ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# “Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру турында” Татарстан Республикасы Законының 10 һәм 15 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2015 елның 20 мартында
кабул ителде

**1 статья**

“Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру турында” 2004 елның 26 июлендәге 43-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 7 (I өлеш); 2007, № 8; 2009, № 6, № 9 – 10; 2011, № 4 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2012, № 3; 2014, № 1 – 2) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 10 статьяда:

а) исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“10 статья. **Ачык акционер җәмгыять акцияләрен, җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятьнең устав капиталындагы өлешләрен, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларының (тарихи һәм мәдәни ядкәрләренең) бердәм дәүләт реестрына кертелгән мәдәни мирас объектларын сатканда конкурс шартларын әзерләү һәм раслау тәртибе**”;

б) 1 өлештә:

“өлешләрен” сүзеннән соң “, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларының (тарихи һәм мәдәни ядкәрләренең) бердәм дәүләт реестрына кертелгән мәдәни мирас объектларын (алга таба – мәдәни мирас объектлары)” сүзләрен өстәргә;

алтынчы абзацта “мәдәни мирас объектларына,” һәм “реставрация,” сүзләрен төшереп калдырырга;

түбәндәге эчтәлекле җиденче абзац өстәргә:

“Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкәрләре) турында” 2002 елның 25 июнендәге 73-ФЗ номерлы Федераль закон белән билгеләнгән тәртиптә мәдәни мирас объектын саклап калу эшләрен үткәрү.”;

2) 15 статьяда:

а) 1 өлештә “аларны саклау йөкләмәләрен алган килеш” сүзләрен “мәдәни мирас объектларын тотуга һәм алардан файдалануга таләпләр, мондый объектларны саклап калуга таләпләр, күрсәтелгән объектлардан файдалана алуны тәэмин итүгә таләпләр куелган килеш” сүзләренә алмаштырырга;

б) 2 өлешне үз көчен югалткан дип танырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Президенты
вазыйфаларын вакытлыча башкаручы Р.Н. Миңнеханов

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ • АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан,Кремль
2015 елның 09 апреле
№ 21-ТРЗ